МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

12.08.2020 Казан ш. № 503-пр

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 01.11.2019 № 570-пр боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләрен физик яисә юридик затларга сатулашулар уздырмыйча арендага яисә милек итеп бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Законнарга үзгәрешләр кертелүенә бәйле рәвештә боерам:

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының «Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләрен физик яисә юридик затларга сатулашулар уздырмыйча арендага яисә милек итеп бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 01.11.2019 № 570-пр боерыгы белән расланган (Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 03.02.2020 № 61-пр боерыгы белән расланган үзгәрешләр белән) Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләрен физик яисә юридик затларга сатулашулар уздырмыйча арендага яисә милек итеп бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган тәкъдим ителгән үзгәрешләрне расларга.

**Министр** **Ф.Ә.Әһлиуллин**

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгының
12.08.2020 № 503-пр
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының «Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләрен физик яисә юридик затларга сатулашулар уздырмыйча арендага яисә милек итеп бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 01.11.2019 № 570-пр боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләрен физик яисә юридик затларга сатулашулар уздырмыйча арендага яисә милек итеп бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган
үзгәрешләр

1 бүлектә:

1.3.5 подпунктның икенче абзацына «мәгълүмати стендлардагы» сүзләреннән соң «һәм Министрлыкның рәсми сайтындагы» сүзләрен өстәргә;

1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне көйләүче норматив хокукый актлар исемлеге (реквизитлары һәм рәсми басылу чыганаклары күрсәтелеп) «Интернет» челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган.»;

1.5 пунктта:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтү күпфункцияле үзәгенең ерактагы эш урыны – Татарстан Республикасының муниципаль районының шәһәр (авыл) җирлегендә яки шәһәр округында «Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк эшчәнлеген оештыру тәртипләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 22 декабрендәге № 1376 карары белән расланган Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк эшчәнлеген оештыру тәртипләренең 34 нче пункты нигезендә оештырылган дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офис) (алга таба – МФЦның ерактагы эш урыны);»;

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) - «Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге №

210-ФЗ Федераль законның (алга таба - № 210-ФЗ Федераль закон) 2 статьясындагы 1 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтүне сорау. Гаризаларның киңәш ителгән формалары әлеге Регламентның 1 кушымтасында китерелгән.»;

2.1 пунктның «Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Җир кодексы (алга таба – РФ ҖК);

«Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 елның 25 октябрендәге № 137-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 137-ФЗ Федераль закон);

Татарстан Республикасы Җир кодексының 4, 18 ст. (алга таба – ТР ҖК);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмәнең 3.3.19 пункты (алга таба – Нигезләмә)»;

2.5 пунктта:

«Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Җир кишәрлеген сатулашулар уздырмыйча милеккә (арендага) бирү турында гариза.

2. Гариза бирүченең җир кишәрлеген сатулашулар уздырмыйча алу хокукын раслаган һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләтләре билгеләгән башкарма хакимиятнең федераль органы исемлеге белән каралган документлар, Министрлыкка ведомствоара мәгълүмати арадашлык тәртибендә бирелергә тиешле документлар искәрмә булып тора.

3. Җир кишәрлеген сатулашулар уздырмыйча милеккә (арендага) бирү турында мөрәҗәгать белән гариза бирүченең вәкиле мөрәҗәгать иткән очракта – гариза бирүченең вәкаләтләрен раслаучы документ.

4. Гариза бирүче чит ил юридик заты булган очракта, юридик затның чит дәүләт законнарына туры китереп дәүләт регистрациясен үтүе турында рус телендә расланган тәрҗемәсе.

5. Җир кишәрлеген сатулашулар уздырмыйча милеккә (арендага) бирү турында мөрәҗәгать белән коммерцияләшмәгән бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәте чыккан булса, әлеге ширкәт тарафыннан әзерләнгән аның әгъзалары реестры.

Әлеге документлар Министрлыкка җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында мөрәҗәгать белән юлланган булса, әлеге мөрәҗәгатьне карап җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында карар кабул ителгән булса, күрсәтелгән документларны тапшыру таләп ителми.

РФ ҖК $39^3$ статьясының 2 пунктындагы 7 подпунктында, РФ ҖК $39^6$ статьясының 2 пунктындагы 11 подпунктында каралган очракларда җир кишәрлеген сатулашулар уздырмыйча гына милек итеп бирү турында мөрәҗәгать әлеге җир

кишәрлеген даими (вакыты чикләнмәгән) куллануның туктатылуы турында мөрәҗәгать белән бергә тапшырылырга тиеш.

РФ ҖК $39^5$ статьясының 4 һәм 5 подпунктларында каралган очракларда җир кишәрлеген милек итеп бирү турында мөрәҗәгать әлеге җир кишәрлеген түләүсез файдалану хокукы беткән көнгә кадәр, әлеге хокукның туктатылуы турында мөрәҗәгать белән бергә тапшырылырга тиеш.

Гариза бирүче тапшыра торган өстәмә документлар исемлеге, хезмәтне алучының категориясенә карап, әлеге Регламентның 10 нчы, 11 нче кушымталарында китерелгән.

Гариза һәм аңа беркетелгән документлар гариза бирүче тарафыннан кәгазь рәвешендә түбәндәге ысуллар белән бирелә (җибәрелә) ала:

шәхсән (ышанычнамә нигезендә гариза бирүче тарафынннан эш итүче зат);

почта аша;

МФЦ аша.

Гариза һәм аңа теркәлгән документлар, техник мөмкинлекләр булганда, «Интернет» мәгълүмати телекоммуникацияләр челтәрен кулланып, «Территориянең кадастр планында җир кишәрлеге яки җир кишәрлекләре урнашу схемасын раслау турында, дәүләт яки муниципаль милектәге җир кишәрлеген сату буенча аукцион үткәрү яисә дәүләт яки муниципаль милектәге җир кишәрлегенә аренда килешүе төзү хокукына аукцион үткәрү турында, дәүләт яки муниципаль милектәге җир кишәрлеген бирү турында алдан килешү турында, дәүләт яки муниципаль милектәге җир кишәрлеген бирү турында гариза бирү ысулларын һәм тәртибен раслау турында һәм дәүләт яки муниципаль милектәге җир кишәрлеген, шәхси милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрен кулланып гариза бирү, шулай ук аларның форматларына куелган таләпләр турында» Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының 14.01.2015, №7 боерыгына (алгат таба - № 7 боерык) туры китерелеп, электрон документ форматында тапшырыла ала. Документларны электрон форматта бирүнең мәҗбүри шарты булып аларга «Электрон имза турында» 6 апрель, 2011 ел, № 63-ФЗ Федераль закон (алга таба - № 63-ФЗ Федераль закон) һәм 27 июль, 2010 ел, № 210-ФЗ Федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза куелу тора»;

«Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

РФ ҖК $39^3$, $39^5$, $39^6$, $39^{15}$ $39^{17}$ ст.;

«Гариза бирүченең җир кишәрлеген сатулашулар үткәрмичә алу хокукын раслаучы документлар исемлеген раслау турында» 12.01.2015, № 1 Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы боерыгы (алга таба – Боерык № 1);

2015 елның 13 июлендәге № 218-ФЗ Федераль закон (алга таба – Федераль закон № 218 – ФЗ)»;

2.6 пунктта:

«Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләп атамасы» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6. Норматив хокукый актларга туры китереп, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган, дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында һәм дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомствосында булган оешмаларда сакланган, гариза бирүче тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук мөрәҗәгать итүченең аларны алу ысуллары, шул исәптән, электрон формада, аларны бирү тәртибе; әлеге документлар карамагында сакланган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма»;

«Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ведомствоара мәгълүмати арадашлык кысаларында түбәндәгеләр алына:

1. Соралган җир кишәрлеге турында Күчемсез милек бердәм дәүләт реестрыннан белешмә (алга таба – ЕГРН) - Татарстан Республикасы буенча Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте идарәсеннән (алга таба - ТР буенча Росреестр).

2. Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан юридик зат турында яисә Шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан шәхси эшмәкәр турында өземтә - Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә (алга таба – ТР буенча ФСХИ);

3. Гариза бирүче инвалид булса яки гаиләсе составында инвалид булса, Россия Федерациясе Пенсия фондыннан (алга таба – РФ ПФ) инвалидлык турында белешмә (инвалидлык танылу фактын раслаучы, инвалидлык группасы күрсәтелгән белешмә; инвалидны, инвалид баланы реабилитацияләү яки абилитацияләү индивидуаль программасы), «Инвалидларның федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмати системасына (ФГИС ФРИ) кертелгән.

4. Гариза бирүченең җир кишәрлеген сатулашулар уздырмыйча алу хокукын раслаган һәм Боерык № 1 белән расланган документлар исемлегендә каралган башка документлар һәм белешмәләр, дәүләт хакимиятенең вәкаләтле федераль органыннан, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органыннан, җирле үзидарә органыннан.

Гариза бирүченең җир кишәрлеген сатулашулар уздырмыйча милеккә, арендага алу хокукын раслаган Министрлыктан сорала торган документлар исемлеге, хезмәтне алучының категориясенә карап, 10 нчы, 11 нче кушымталарда китерелгән.

Гариза бирүче әлеге пунктта күрсәтелгән белешмәләр булган документларны үз инициативасы белән тапшыра ала, шул исәптән, техник мөмкинлекләр булган очракта электрон формада да.

Гариза бирүченең өстә күрсәтелгән документларны тапшырмавы дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен документлар кабул итеп алудан баш тартуга сәбәп булып тормый.

Гариза бирүче тапшырырга хокуклы документларын алу һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән.

Гариза бирүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә килеп чыккан мөнәсәбәтләрне көйли торган норматив хокукый актларда каралмаган документларны һәм мәгълүматны бирүне яки гамәлләр башкаруны таләп итү;

Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары нигезендә, дәүләт хезмәте күрсәтүче дәүләт органнары карамагында, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы башка дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында һәм (яисә) оешмаларда булган документлар һәм мәгълүмат бирелүне, шулай ук, аларны алу өчен түләү кертелүен раслаган докуемнтларны сорау. №210-ФЗ Федераль законның 7 статьясындагы 6 өлешендә каралган документлар искәрмә булып тора;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен яки дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән беренчел баш тартканда белешмәнең булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгәндә. №210-ФЗ Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешендә 4 пунктында күрсәтелгән очраклар искәрмә булып тора»;

«Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«РФ ҖК $39^{17}$ ст.;

№ 1 Боерык;

“Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булып торучы һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтүдә катнашучы оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр исемлеген раслау турында” 13.08.2011, № 675 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – № 675 ТР МК карары)»;

2.12 пунктның «Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы № 601 Россия Федерациясе Президенты Указы, 1 п.»;

3 бүлектә:

3.4.1 подпунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Бүлек белгече Эш башкару бүлегеннән гаризаны һәм документларны алгач Министрлыкта гариза үтү битен тутыра (2нче кушымта) һәм ведомствоара электрон арадашлык системасы аша электрон формада запрослар юллый:

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан гариза бирүче булган юридик зат турында белешмә бирү турында, яисә Шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан гариза бирүче булган шәхси эшмәкәр турында белешмә бирү турында ТР буенча ФСХИдан;

күчемсез милек объекты турында (соралган җир кишәрлеге турында) ЕГРНнан өземтә бирү турында ТР буенча Росреестрдан;

гариза бирүче инвалид булса яки гаиләсе составында инвалид булса, Россия Федерациясе Пенсия фондыннан (алга таба – РФ ПФ) инвалидлык турында белешмә бирү турында (инвалидлык танылу фактын раслаучы, инвалидлык группасы күрсәтелгән белешмә; инвалидны, инвалид баланы реабилитацияләү яки абилитацияләү индивидуаль программасы), «Инвалидларның федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмати системасыннан (ФГИС ФРИ);

гариза бирүченең җир кишәрлеген сатулашулар уздырмыйча алу хокукын раслаган һәм Боерык № 1 белән расланган документлар исемлегендә каралган башка документлар һәм белешмәләр бирү турында дәүләт хакимиятенең вәкаләтле федераль органына, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органына, җирле үзидарә органына.

Әлеге пункт билгеләгән процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: белешмә (документлар) бирү турында запрослар.»;

3.5.7 подпунктны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Процедуралар нәтиҗәсе: хокук идарәсе башлыгы тәкъдимнәре белән эшкәртелгән һәм хокук идарәсе башлыгына юлланган арендага яки милеккә бирү турында карар проекты, аренда яки сату-алу шартнамәсе проекты, яисә баш тарту турында карар проекты.»;

3.5.9 подпунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Процедуралар нәтиҗәсе: хокук идарәсе башлыгы белән килештерелгән, министрның беренче урынбасарына юлланган арендага яки милеккә бирү турында карар проекты, аренда яки сату-алу шартнамәсе проекты, аренда яки сату-алу шартнамәсе проекты белән бергә юллана торган хат, яисә баш тарту турында карар проекты.»;

5.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.5. Гариза бирүче тарафыннан бәян ителгәннәрне раслый торган документлар (булса), яки аларның күчермәләре тапшырыла ала.».

10 нчы кушымтаның 19 подпунктында «Гариза бирүченең җир кишәрлегенә сатулашулар уздырмыйча ия булу хокукын раслаучы һәм җир кишәрлегенә хокукка ия булу турында гаризага теркәлә торган документлар» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«* Вәкаләтле орган тарафыннан бирелгән, гражданинның җир кишәрлекләренә беренче чиратта яки чиратсыз ия булырга хокуклы гражданнар категориясенә керүен раслаган документ
* Күчемсез милек объекты турында (соралган җир кишәрлеге турында) ЕГРНнан өземтә;».